**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Югары Кәминкә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**карары**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге составына керүче Югары Кәминкә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 октябрендәге 1 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге составына керүче Югары Кәминкә торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 2023 елның 23 октябрендәге 2 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенең Югары Кәминкә торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында

16 март 2024 ел №  2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Уставы нигезендә гражданнар җыенына түбәндәге мәсьәлә чыгарылды:

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенең Югары Кәминкә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 октябрендәге 1 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенең Югары Кәминкә торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 2023 елның 23 октябрендәге 2 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенең Югары Кәминкә торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү белән һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрү белән килешәсезме:

- **тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** (Югары Кәминкә торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алыштыру);

- **су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче су башнялары, скважиналар һәм башка инженерлык корылмаларының су белән тәэмин итү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (Су белән тәэмин итү чыганаклары

территориясен санитар саклау зонасын саклау җайланмасы, кирәкле материаллар сатып алу, Югары Кәминкә авылы торак пунктында эчәр су анализларын үткәргән өчен түләү, насослар һәм кирәкле материаллар сатып алу);

- **яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту** (туфракны (балчыкны) чыгару, Югары Кәминкә авылы торак пунктында биек агачларны кисү, кирәкле кораллар һәм материаллар сатып алу, эш (хезмәт күрсәтү) өчен түләү);

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** (Югары Кәминкә торак пунктында җирле әһәмияттәге урам юлларын чокырлы ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу)

- **Торак пункт территориясен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдировкалау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, Югары Кәминкә торак пунктында ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, кирәкле материаллар һәм юл билгеләре сатып алу, кирәкле материаллар сатып алу, эш (хезмәтләр) өчен түләү).

- **Коймаларны ремонтлау, урнаштыру, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (коймаларны ремонтлау, урнаштыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу, дератизация чаралары өчен түләү, коры агачларны, куакларны кисү, үләнне чабу).

**Гражданнар җыены карар кылды:**

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенең Югары Кәминкә торак пунктында халык җыены **булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.**

3. Киләсе карарны: «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенең Югары Кәминкә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 октябрендәге 1 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенең Югары Кәминкә торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 2023 елның 23 октябрендәге 2 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенең Югары Кәминкә торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында» түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә:

- **урам яктырту җайланмасы** (тышкы яктыртуның урам челтәрләрен ремонтлау, Югары Кәминкә, Керкәле, Кызыл Яр торак пунктларында урам яктыртуын урнаштыру, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- **су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче су башнялары, скважиналар һәм башка инженерлык корылмаларының су белән тәэмин итү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче су башнялары, скважиналар һәм башка инженерлык корылмаларының су белән тәэмин итү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау. Су белән тәэмин итү чыганаклары территориясен санитар саклау зонасын төзекләндерү, Югары Кәминкә авылы, Керкәле авылы, Кызыл Яр авылы торак пунктларында эчәр суны анализлау өчен түләү);

- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (яр буе зоналарын, елга үзәненең сулыкларын чистарту, туфракны (ләмне) чыгару, Югары Кәминкә авылы, Керкәле авылы, Кызыл Яр авылы торак пунктларында биек агачларны кисү);

- **Коймаларны ремонтлау, урнаштыру, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (коймаларны ремонтлау, урнаштыру, традицион күмү урыннарын төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, дератизация чараларына түләү;

- **Торак пункт территориясен төзекләндерү** (халыкның массакүләм ял итү урыннарын, балалар мәйданчыкларын, спорт мәйданчыкларын, паркларны, яр буйларын һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү, ремонтлау, адреслы такталар ясау, торак пункт чикләрендә җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту, аларга хезмәт күрсәтү, җәяүлеләр күперләрен һәм юл кичүләрен ремонтлау, ягулык-майлау материаллары, кирәкле материалларның запас өлешләрен сатып алу, хезмәтләр өчен түләү **кабул ителгән дип танырга.**

4. Югары Кәминкә авылы, Ленин урамы, 19 йорт, Керкәле авылы, Дуслык урамы, 7 йорт, Кызыл Яр авылы, Ленин урамы, 13 йорт мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам

**Халык җыенында рәислек итүче**
**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Югары Кәминкә авыл җирлеге башлыгы** **М.Н.Минһаҗев**